СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.10.2020 Баулы шәһәре № 13

Баулы муниципаль районы Советының
2005 елның 12 ноябрендәге «Эшчәнлекнең
аерым төрләренә кертелгән керемгә бердәм
салым рәвешендә салым системасын
гамәлгә кертү турында» 2/10 номерлы
карарын гамәлдән чыгару турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» Федераль законның 26 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 29 июнендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның (Федераль законның 2016 елның 2 июнендәге 178-ФЗ номерлы редакциясендә) 5нче статьясы 8нче пункты нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының 2005 елның 12 ноябрендәге «Эшчәнлекнең аерым төрләренә кертелгән керемгә бердәм салым рәвешендә салым системасын гамәлгә кертү турында» 2/10 номерлы карарын (2005 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы, 2006 елның 23 ноябрендәге 313/3 номерлы, 2007 елның 25 октябрендәге 130 номерлы, 2008 елның 31 октябрендәге 183 номерлы, 2008 елның 9 декабрендәге 197 номерлы, 2012 елның 8 ноябрендәге 145 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә https://bavly.tatarstan.ru адресы буенча Баулы муниципаль районы сайтында һәм https://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы Рәисе Р.Х. Гатиятуллин